**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**08.09.2021** **№ 41**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 27 декабрендәге 26 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 27 декабрендәге 12 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 2.3 пунктта «2 йорт» сүзләрен «2а йорты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Г. Нургалеев**